**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительного комитета**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево,
423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай
шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«16» октябрь 2019 ел** **№ 305**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 02.06.2015 ел №137 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясен планлаштыру буенча документлар әзерләү тәртибе турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясен планлаштыру буенча документлар әзерләү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында
(26.02.2019 №48 карар редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 02.08.2009 ел, №283-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясе җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел № 131 - ФЗ Федераль закон нигезендә, карар чыгарам:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 02.06.2015 ел №137 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясен планлаштыру буенча документлар әзерләү тәртибе турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясен планлаштыру буенча документлар әзерләү Тәртибенә (26.02.2019 №48 карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.4 пунктның өченче абзацында «муниципаль районның территориаль планлаштыру схемасы» сүзләреннән соң, территориягә карата аның комплекслы һәм тотрыклы үсеше буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру күздә тотыла торган территорияләр» сүзләрен өстәргә;

1.2. 2.1 пунктның беренче абзацында «1.1 өлешендә» сүзләрен «1.1 һәм 12.12 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 2.9 пунктта «30 көн» сүзләрен «егерме эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 2.10 пунктының икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) территорияне планлаштыру буенча документация буенча иҗтимагый фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрү, ә әлеге Тәртипнең 2.13 пунктында каралган очракта, мондый документацияне раслау турында;

2) о направлении на доработку документации по планировке территории.».

1.5. 2.13 пунктының беренче абзацында «әгәр алар» сүзләрен «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексының 43 статьясындагы 12 өлешендә каралган очракта, шулай ук территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru/.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура буенча урынбасары
Р. Р. Ханнановка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
икътисад һәм финанслар буенча җитәкче урынбасары Г.Г.Сөләйманова